Пр.Др. Халюк Нурбаки

Җомга һәм анын әһәмияте

“Дәгъвәт” нәшрияте

Бастыру өчен җаваплы: Илшат хәзрәт Хафизи

Күмәртәләп алу өчен: Казан шәһәре, Париж коммунасы урамы 25/39, 2-че кат, 205-нче бүлмә ″Рамазан″кибетенә мөрәҗәгать итергә. Телефондар: 8-927-430-35-36; 8-927-460-4333
Уфада: 8-937-30-33-734; 8-903-311-80-53 телефоннарына мөрәҗәгать итергә.

Офсет ысулы белән басылды. Форматы Формат 60 x 90 $^{1}/_{16}$. Тиражы 1000 данә.
“Дәгват” нәшрияте. Тел: 8-903-311-80-53. E-mail: ilchat@mail.ru

بِسْمِ اللهِ الرَّحْمَنِ الرَّحِيمِ

Кереш сүз

Хәмдү сәна галәмнәрнең Раббысына, җәза көненең патшасына, хакимнәрнең хакименә, Аллаһ ‘Азимушшанга булса иде.

Саләтү вә сәламнәребез Аллаһның соңгы илчесенә, ике җиһан әфәндесенә, галәмнәргә рәхмәт буларак җибәрелгән Мөхәммәд (сагв.) гә, аның гаиләсенә һәм әсхәбенә җитешсә дә. Инсанлык тарихының иң бөек хакыйкәте, һичшөбһәсез ки, Исламдыр. Ислам бөтен кешелеклелекне кочагында тотып торучы иләһи бер дәгвә ул. Ислам – тугры юл һәм камиллекнең үзе ул. Иләһи бәйән шулай дип боера:

إِنَّ الدِّينَ عِندَ اللهِ الإِسْلاَمُ

“Аллаһ янында бердәнбер дөрес булган дин – Исламдыр”[1].

الْيَوْمَ أَكْمَلْتُ لَكُمْ دِينَكُمْ وَأَتْمَمْتُ عَلَيْكُمْ نِعْمَتِي
وَرَضِيتُ لَكُمُ الإِسْلاَمَ دِينًا

“Динегезне камил итүем белән, бүген сезгә тиешле булган нигъмәтләремне тәмамладым. Разы булган дин буларак та, сезгә Ислам динен игълан иттем”[2].

Аллаһ Сөбһанаһү вә Тәгаләнең кешеләр өчен сайлаган, разы булган һәм Үзе тарафыннан камилләштерелгән Ислам дине, иман, гыйбәдәт, әхлак, хокук, икътисад һәм идарә системалары белән бербөтен тәшкил итә. Шуңа күрә кем яшәешен бу системага корып, үзен дә шуңар тәслим итә белсә, чын мәгънәдә мөселман булыр.

---

[1] Али Имран: 19
[2] Әль-Мәидә: 3

Кеше тормышына кагылышлы барлык мәсьәләләрдә хөкеме булган Ислам дине, ышану өчен генә түгел, тормышның һәр мизгелендә кулланылу өчен җибәрелгән. Шуңа күрә дә инсанлык әгәр бәхет һәм сөенеч тели икән, Исламга ашыгырга тиеш. Тормыш һәм яшәешен Ислам сызыклаган план буенча яшәргә теләмәгән инсанлык исә сөенеч һәм бәхеттән ерак калачак.

وَمَن يَبْتَغِ غَيْرَ الإِسْلاَمِ دِينًا فَلَن يُقْبَلَ مِنْهُ وَهُوَ فِي الآخِرَةِ مِنَ الْخَاسِرِينَ

“Кем Исламнан кала башка бер дин эзләргә керешсә, аның дине кабул булмас, ахырәттә дә андыйлар кайгы хәсрәттә булырлар”[3].

Димәк ки, коткаручы бер генә дин бар, ул да булса Ислам динедер. Исламның мөэминнәргә ихсан иткән иң олы гыйбәдәт көне исә - Җомга көнедер.

عن ابى لبابة بن عبد امنذررضى الله عنه قال: قال رسول الله (ص): ان يوم الجمعة سيد الايام، و اعظامها عند الله. و هو اعظم عند الله من يوم الاضحى ويوم الفطر. و فيه خمس خلال: خلق الله فيه ادم، و أهبط الله فيه ادم الى الارض، و فيه ساعة لا يسأل الله فيها العبد شيا الا اعطاه و لم يسأل حراما، و فيه تقوم الساعة، ما من ملك مقرب و لا سماءٍ و لا ارضٍ و لا ريا و لا جبال و لا بحر إلا و هن يشفقن من يوم الجمعة.

رواه ابن ماجة

“Көннәрнең иң бөеге һәм иң олысы – һичшиксез, җомга көнедер. Җомга көненең Аллаһ Тәгалә каршысындагы бөеклеге Корбан һәм Ураза гаетләренекеләреннән дә олырак. Бу көннең биш

---

[3] Али Имран: 85

фазыйләте бар: бу көнне Адәм яратылды, шул үк көнне ул җиргә төшерелде һәм шул ук җомга көнендә вәфат та булды, бу көндә барлык догаларның кабул ителү сәгате бар, кыямәт кубуы җомга көнендә булыр. Һәм һавада, җирдә яки суда нинди генә җан иясе булмасын – һәрберсе җомга көненең олылыгыннан тетрәп калтырар".

Җомга – "Минбәр" дип аталган пәйгамбәр макамыннан "Хөтбә" уку, ягъни зикер кылу һәм угет-нәсихаттә булыну ул. Җомга көнне, хөтбә уку белән вазыфәләндерелгән Имам һәм хатыйб кардәшләребезгә, мәчетләргә Аллаһ хозурына ашыгып килгән мөселманнарның күңелләренә хөтбә ирад итү һәм аларга Исламның коткаручы дәгвәсе турында хәтерләтү тиешле. Бу вазыфәне чиста күңел һәм чын тырышлык белән үтәмәүчеләр исә бөек бәла эченә кермеш саналырлар.

Тырышлык бездән булса, ярдәм, Рахман һәм Рәхим булган Аллаһтандыр. Ялгыз Аңа гына коллык итәбез һәм Аңардан гына ярдәм сорыйбыз.

Җомга намазы һәм җомга хөтбәсе

Кояш калыккан көннәрнең иң хәерлесе булган җомга көненең, мөэминнәрнең дини һәм иҗтимагый тормышларында бик шәрәфле урыны бар. Исеме белән Көрьән-и Кәримнең бер сүрәсе исемләнгән җомга, мөэминнәрнең гыйбәдәт һәм бәйрәм көне. Җомга – мөэминнәрнең мәгънәви җыелып-киңәшләшүе ул. Җомга хөтбәләре мөэминнәр өчен бер дәрес һәм гыйлем алмашу.

Җомга көне мәчетләргә ашыгып килүче мөэминнәр, тыңлаган хөтбәләр һәм кылган намазлар сәбәпле күңелләрендәге пычраклыклардан чистарынырга тырышырлар. Бу, мөэминнәргә, көнлек гыйбәдәтләреннән

тыш, һәр атна саен рухи чистарыну өчен бирелә торган гыйбәдәт. Сөекле пәйгамбәребез (сагв.) бер хәдис-и шәрифендә шулай дип әйтә:

عن سلمان الفارسى رضى الله عنه قال: قال رسول الله (ص): لا يغتسل رجل يوم الجمعة و يتطهر ما استطاع من الطهر، و يدهن من دهنه او يمس من طيب بيته، ثم يخرج فلا يفرق اثنين، ثم يصلى ماكتب له، ثم ينصت اذا تكلم الامام الا غفر له ما بينه و بين الجمعة الاخرى. رواه البخارى.

“Кем җомга көнне, госелләнеп, яхшы киемнәрен киеп һәм исле майлар сөртенеп, этешмичә мәчеткә җомга хөтбәсен тыңларга килсә, имам минбәргә менеп, намазыннан аерылганчыга хәтле эндәшмичә хөтбәсен тыңлап, намазын кылса, аның ике җомга арасындагы гөнәһлары гафу ителер”[1].

Җомга көнне өйлә вакытында кылынган җомга намазы, һиҗрәтнең беренче елында үк фарыз кылынды. Тәбаранинең риваяте буенча исә, ул һиҗрәттән әввәл үк фарыз кылынып, Мәдинәдә укыла башлады. **Үзенең беренче җомга намазын пәйгамбәребез (сагв.) Мәдинә-и Мөнәввәрәгә һиҗрәте вакытында, Рануна исемле даладагы мәчеттә кылмыш[2].**

Җомганың фарызлылыгы китап, сөннәт һәм иҗмаг-и өммәт тарафыннан исбат ителгән. Аны инкяр итү – көфер санала.

Җомга намазы алдыннан хөтбә уку фарыз булганы кебек үк, шартларын үтәгән мөэминнәр өчен җәмагать белән ике рәкагать җомга намазын кылу да фарыз эль-гәйн булып санала. Җомга намазының сигез рәкагать сөннәте бар:

---

[1] Әбү Дауд, әт-Таж том 1: 280

[2] Ислам Энциклопедиясе, Җомга һәм Хөтбә өл.

боларның дүртесе фарыздан әввәл, дүртесе дә ахырдан кылына. Иң соңында исә дүрт “зухр әль-ахыр” исемле ике рәкагатьлек намаз тагын кылыныр, әмма моның турында мөҗтәһидләрнең фикере төрле.

Җомга намазы фарызлылыгының дәлилләре

1-Аятләр

يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا إِذَا نُودِي لِلصَّلَاةِ مِن يَوْمِ الْجُمُعَةِ فَاسْعَوْا إِلَى ذِكْرِ اللَّهِ وَذَرُوا الْبَيْعَ ذَلِكُمْ خَيْرٌ لَّكُمْ إِن كُنتُمْ تَعْلَمُونَ فَإِذَا قُضِيَتِ الصَّلَاةُ فَانتَشِرُوا فِي الْأَرْضِ وَابْتَغُوا مِن فَضْلِ اللَّهِ وَاذْكُرُوا اللَّهَ كَثِيرًا لَّعَلَّكُمْ تُفْلِحُونَ

“Әй, иман итүчеләр, җомга көнне намазга чакырылганыгызда, Аллаһны зикер итәргә ашыгыгыз, сәүдәләрегезне дә туктатыгыгыз. Бу, әгәр белсәгез икән, сезнең өчен хәерлерәк. Намазларыгызны бетергәч, таралып, Аллаһ фазылыннан ризык эзләвегезне дәвам итегез, шулай гына морадларыгызга ирешерсез”[3].

2-Хәдисләр

Җомга намазының фарызлылыгы турында күп кенә хәдис-и шәриф бар. Монда аларның кайберләрен генә китерәбез:

“Җомга намазын җәмагатьтә кылу һәр мөселман өчен фарыз. Кол, хатын, бала һәм авырулара исә ул фарыз түгел”[4].

“Һичнинди сәбәпсез җомга намазын калдыручы кемсәләрнең исемнәре язулары һичкайчан югалмаган китапта мөнафик буларак язылыр”[5].

---

[3] Әль-Җомга: 9-10

[4] Әбү Дауд, Бәйхаки, Хаким әт-Таҗ том 1: 274

“Әгәр дә сәбәпсез җомга намазларын калдыруны туктатмасгыз, Аллаһ кальбләрегезгә андый бер мөһер сугар ки, мәңгелеккә гафил калырсыз”[6].

“Әй, кешеләр, белегез ки, бу көннән алып, кыяматкә хәтле, җомга көне намазы сезгә фарыз ителә. Имамнарыгыз начар яки яхшы булсын, җомганы әһәммиятсез күреп, аны калдыручыларның эше яхшылык белән бетмәячәген белеп торыгыз”[7].

“Җомга намазында имам буларак башканы билгеләп, үземнең дә, валлаһи, җомгага килмәгәннәрнең өйләренә ут төртеп чыгасым килә”[7].

Югарыда зикер ителгән аят-и кәримәләр һәм хәдис-и шәрифләр җомга намазының фарызлылыгына дәлил булып торалар.

Эшне туктатып җомгага бару

Җомга көнне икенче җомга азаны укылу белән, эшне калдырып мәчеткә юнәлү фарыз булып санала. Хәнәфи мәзхәбе буенча исә, манаралардан беренче җомга намазы ишетелү белән җомга фарыз булган мөселманга эшләрен калдырып намазга юнәлү фарыз була.

Пәйгамбәребез (сагв.) минбәргә чыккан вакытта, мөәззин азан укыр, артыннан да рәсүлүллаһ (сагв.) хөтбәсен башлар иде. Мөселманнар күбәйгәч, хәлифә Госман (р.а.) нан башлап, азан ике тапыр укыла торганга әйләнде. Мөҗтәһид факихлар бу ике азанның кайсысы беренче азан икәнлеге турында төрле фикер йөртә башладылар, әмма хәнәфи мәзхәбе буенча, мәчеткә, эшне туктатып, беренче азан ишетелү белән китү тиешле.

---

[5] Шафигый, әт-Таҗ том 1: 274

[6] Муслим, Рияд ас-Салихин тәрҗ. том 2: 441

[7] М.А.Кёксал, Мөхәммәд һәм Исламият том 1: 21

[7] Муслим, Дүрт Мәзхәбнең Фикх Китабы том 1: 334

Җомгага бару өчен рөхсәт сорау

Җомга көне хөтбәсенә барып, намазын кылу, шартларын ташучы һәрбер мөселман өчен Аллаһ әмере – фарыз булып тора. Бу фарызны җиренә җиткерү һәр мөэминнең вазыфәсе һәм хаккы. Нинди генә эштә һәм нинди генә вазыфәдә булмасын, мөселманнарга бу хакларын куллану өчен мөмкинлек бирү һәркемнең бурычы. Шуңа күрә җомга көннәрне эшчеләргә, иң әз дигәндә, җомга намазы кылырдай вакыт бирүне дә истә тоту тиешле. Бу дини бер вазыфәнең үтәлүе һәм мөэминнәр арасында берлек һәм кардәшлелекнең көчләнүе өчен бер шарт булып тора.

Җомга намазының шартлары

Җомга намазының шартлары, аның фарызлылыгы һәм дөреслелеге ягыннан ике төргә бүленә.

А-Фарызлылык шартлары:

1-Ир кеше җенесендә булу. Җомга намазы хатыннарга фарыз түгел.
2-Хөр һәм азат булу. Кол һ.б.ларга җомга фарыз түгел.
3-Мукыйм булу. Дин буенча юлчы (мөсафир) саналучыларга җомга намазы фарыз түгел.
4-Сау-сәламәт булу. Йөри алмаслык кадәр карт һәм мәчеткә хәтле барып җитә алмаслык кадәр авыруларга җомга намазы фарыз түгел.
5-Аяк һәм күзләрнең сәламәт булуы. Параличлылырга һәм ике күзгә сукыр булганнарга җомга намазы фарыз түгел.
6-Намазга китмәү өчен билгеле чикләүләрнең һәм сәбәпләрнең булмавы. Мәсәлән каты яңгыр, кар һәм бозлавык булганда яки дошманнан курыккан вакытта җомгага бару фарыз түгел.

Бу шартларга мөнасиб төшкән кемсәләргә җомга

намазын кылу фарыздыр. Җомга намазы фарыз булмаган кемсәләргә исә, гадәттәгечә өйлә намазын кылу тиешле. Җомга намазын кылучылар исә, намазларын кылу белән өйлә намазларын да кылмыш булырлар, шуңа күрә аларга өйлә намазын кылу кирәкмәс.

Б-Дөреслелек шартлары

Кылынмасы фарыз булган җомганың дөрес булуы өчен астагы шартларның үтәлүе тиешле:

1-Җомга намазының өйлә вакытында кылынуы. Җомга намазы өйлә намазы вакытыннан әввәл дә кылына алмаганлыгы кебек үк, өйлә намазы вакыты чыккач та кылынмас. Җомга намазының казасы юк.

2-Намаздан әввәл хөтбә укылырга тиеш. Җомга хөтбәсе нияте белән укынган бу хөтбә, җәмагатьтән иң әз дигәндә бер кеше алдында да укына ала. Җәмагатьсез яки намазга гына җыелган җәмагать белән укынган хөтбә һәм кылынган намаз дөрес саналмас.

3-Җомга намазында имамнан тыш җәмагать буларак өч ирнең булуы.

4-Җомга намазы кылынган урын һәркемгә билгеле һәм һәркем өчен ачык булуы.

5-Җомга намазын кылдырган кемсәнең намазын кылдыру өчен рөхсәте булуы. Рөхсәте булган кемсә үзе урынына башканы да билгели ала.

6- Җомга намазы кылынган урын шәһәр чикләре эчендә булырга тиеш. Шәһәр исә - кеше яшәгән һәм кешеләр ихтияҗ күргән урын астында билгеле, шуңа күрә җомга намазлары бу васыфлары булган авылларда да кылыныр.

Җомга хөтбәсе һәм аның шартлары

Җомга хөтбәсе фарыз һәм җомганың дөрес булуы өчен бер шарт булып тора. Хөтбәсез җомга намазы дөрес

саналмас. Җомга хөтбәсе намаздан әввәл укылыр. Бәйрәм хөтбәләре исә сөннәт булганга күрә, намаздан соң укылыр.

Хөтбә - зикер һәм нәсыйхатьтер. Һәр хөтбә ике өлешкә бүленә. Хөтбәнең беренче өлеше икенче өлешеннән аерылуы, хатыйбның бераз утырып алуы белән башкарыла. Хөтбәнең һәр ике өлешендә дә Аллаһка хәмд-ү сәна, пәйгамбәргә (сагв.) саләт-ү вә сәлам китерелер. Хөтбәнең беренче өлешендә Аллаһка хәмд-ү сәна китерелеп, мөселманнарга үгет-нәсыйхать бирелер, икенче өлешендә исә хәмд-ү сәна китерелеп дога кылыныр.

Хөтбәнең рөкеннәре

Хөтбәнең иң әһәмиятле рөкеннәреннән Аллаһ Сөбһанаһү вә Тәгаләне зикер итү. Шуңа күрә хөтбәдә **“Сөбһаналлаһи, әлхәмдүлилләһи, лә иләһа илләллаһ”** кебек тәсбиһатлар әйтелсә дә, хөтбәнең иң әһәмиятде рөкене җиренә җиткерелгән дип санала. Ләкин бу тәсбиһатлар бик кыска да булмаска тиеш һәм эчендә пәйгамбәребезгә (сагв.) саләт-ү вә сәлам китерү дә кирәк дип санала.

Хөтбәнең дөрес булу шартлары

1-Хөтбәне җомга намазы вакытында уку.
2-Хөтбәне җомга намазы алдыннан уку.
3-Хөтбәне хөтбә нияте белән укый башлау.
4-Хөтбәне җәмагать каршында уку.
5-Хөтбә белән җомга намазының фарызы арасындагы вакыт эчендә намаздан кала бернәрсәгә дә аерылмау.

Хөтбәнең сөннәтләре

1-Минбәргә чыкканчы хатыйбның минбәр янында булуы.
2-Минбәргә чыккач, хатыйбның җәмагатькә борылып,

укынган азанны тыңлау.
3-Хөтбәне минбәр өстендә уку.
4-Хатыйб чыккач икенче (мәчет) азанының укылуы.
5-Хөтбәне ике өлешкә бүлү.
6-Ике хөтбә арсында бераз утырып тору.
7-Хөтбәнең ике өлешендә дә хәмд, салават һәм шәһәдәт кәлимәләрен әйтү.
8-Хөтбәнең ике өлешен дә җәмагатькә борылган килеш һәм аякта уку.
9-Мөэминнәргә үгет-нәсыйхатьтә булу.
10-Хөтбәнең икенче өлешендә мөэминнәр өчен дога кылу.
11- Хөтбәнең ике өлешен дә кыска тоту.
12-Хөтбәне һәркемгә ишетерлек иттереп сөйләү.
13-Көрьән-и Кәримнән бер аят уку.
14-Хөтбәне тавыш-тынсыз тыңлау.
15-Хөтбәне башлаганчы эчтән әгүзе-бисмилла уку.
16-Сугыш белән яуланган шәһәрләрдә хөтбәне кулда кылыч тотып сөйләү.
17-Хөтбәнең икенче өлешендә тавышны бераз түбәнәйтү.
18-Хөтбә беткәч камәт төшерү.

Хөтбәнең сөннәтләре кыскача болар. Бу сөннәтләрнең калдырылуы мәкрүһ булып санала.

Җомганың фазыләте һәм аның тәртибе

Госелле булу

Җомга – мөэминнәрнең атналык гыйбәдәтләре һәм иҗтимагый көннәре. Бу көн госелләнеп мәчеткә бару бөек бер фазыләттер. Сөекле пәйгамбәребез (сагв.) һәм аның эзеннән йөрүче бу өммәтнең олылары җомга көннәрне госелләнүне иң хәерле эшләрдән күреп, мөэминнәрне дә моңа өндәүчеләрдән иделәр. Моның турында

пәйгамбәребезнең (сагв.) күп кенә хәдисләре бар, боларның кайберләре шулар:

“Сездән берәрегез җомга намазына барырга уйласа геселләнсен”[8].

“Мөселманны җиде көндә бер тапкыр геселле булуын сорау Аллаһның хаккы”[9].

“Җомга көннәрне җөнөб булмасагыз да геселләнеп башларыгызны юыгыз”[10].

“Җомга көннәрне госел коену бәлигъ булган һәркемнең шәхси бурычы”[11].

Чиста кием кию һәм исле майлар куллану

Динебез чисталык динедер. Мөселман кеше һәрвакыт һәм һәрҗирдә чиста булырга, җомга көннәрне дә тагын да чистарак һәм пөхтәрәк булырга тырышачак. Җомга хөтбәләренә иң матур һәм иң чиста киемнәрен киеп килергә тырышачак. Чөнки җомга көнне чиста киемнәр киеп, исле майлар сөртенеп, тырнаклар кисеп, чәч-сакалларны тарап мәчеткә килү - җомганың фазыләтләреннәндер. Пычрак киемнәр һәм исле носкилар киеп мәчеткә килү гөнаһтыр. Болар турында сөекле пәйгамбәребез (сагв.) хәдис-и шәрифләрендә шулай дип әйтә:

---

[8] Бухари, Муслим, Әбү Дауд, Тирмизи, Нәсаи эт-Таҗ том 1: 279
[9] Тәҗрид тәрҗ. том 3: 49 № 488
[10] Тәҗрид тәрҗ. том 3: 27 № 482
[11] Бухари, Муслим Рияд ас-Салихин тәрҗ. том 2: 442 № 1156

“Һәр мөселман, җомга житкәч, тешләрен чистартып, госел алып, чиста киемнәрен киеп һәм, бар икән, исле майлар сөртенеп, мәчеткә килергә тиеш”[12].

“Эш киемегездән кала җомгага бару өчен сезләр бер кат чиста кием дә тотсагыз ни күркәм булыр иде”[13].

Җомгага иртәрәк һәм җәяүләп бару

Җомга көнне госелләнеп, исле майлар сөртенеп, чиста киемнәр киеп, җәяүләп мәчеткә бару - бөек сәваплардан санала. Моның турында пәйгамбәребезнең (сагв.) күп кенә хәдисләре бар, боларның кайберләре шулар:

عن ابى هريرة رضى الله عنه قال: قال رسول الله (ص) اذا كان يوم الجمعة وقفت الملائكة على باب المسجد يكتبون الاول فالاول، و مثل المهجر كمثل الذى يهدى بدنةً، ثم كالذى يهدى بقرة، ثم كبشا، ثم دجاجة، ثم بيضة، فاذا خرج الامام طووا صحوفكم و يستمعون الذكر. رواه البخارى

“Җомга көнне мәчетнең һәр ишеге алдына фәрештә килеп, җомгага килүчеләрне гамәлләр дәфтәренә чиратлап яза башлый. Имам минбәргә чыгып, хөтбәсен укы башлагач, фәрештәләр дә дәфтәрләрен ябып, имамның хөтбәсен тыңлый башлый. Шулай итеп, мәчеткә көндезнең иртә сәгатьләрендә килгүчеләр, бер дәвәлек әҗер-савапка лаек төшәләр. Моннан соңырак килгүчеләр – бер тавыклык әҗер-савапка, моннан соң килгүчеләр дә - бер йомыркалык әҗер-савапка лаек төшәләр”[14].

---

[12] Тәҗрид тәрҗ. том 1: 33

[13] Әбү Дауд, Ибн-и Мажа том 1: 279

[14] Әбү Дауд, Ибн-и Мажа әт-Таж том 1: 286

عن يزيد بن ابى مريم رحمه الله قال: لحقنى عباية بن رفاعة رحمه الله و انا ماش الى الجمعة فقال: أبشر، فانا خطاك هذه فى سبيل الله، سمعت ابا عباس رضى الله عنه يقول: قال رسول الله (ص): من اغبرت قدماه فى سبيل الله فهما حرام على النار. رواه الترمذى

"Кем җомганың иртәнге сәгатьләрендә госелләнеп, мәчеткә җәяүләп килсә, аннары да бер сүз дәшмичә хөтбә тыңлап намаз кылса, мәчеткә атлап килгән һәр адымы өчен бер еллык ураза һәм намаз әҗеренә лаек төшәр"[15].

Башкаларга кыенлыклар тудырудан тыелу

Динебездә намаз гыйбәдәтен беренче сафларда башкару бик саваплы эшләрдән санала. Ләкин мәчеткә соң килүчеләргә намаз кылу өчен урынны беренче сафларда табу һәрвакытта да мөмкин булмый. Шуңа күрә дә, мәчеткә иртәрәк килү хупланган эш булып საналса, мәчеткә соң килеп, анда иртәрәк килеп җыелгучыларга кыенлыклар тудыру – тыелган эшләрдән булып санала. Моның турында пәйгамбәребез (сагв.) үзенең хәдис-и шәрифләрендә шулай дип әйтә:

عن سلمان الفارسى رضى الله عنه قال: قال رسول الله (ص): لا يغتسل رجل يوم الجمعة و يتطهر ما استطاع من الطهر، و يدهن من دهنه او يمس من طيب بيته، ثم يخرج فلا يفرق اثنين – و في الرواية - **لم يؤذ أحدا، ثم يصلى ماكتب له، ثم ينصت اذا تكلم الامام الا غفر له ما بينه و بين الجمعة الاخرى.** رواه البخارى و احمد.

---

[15] Әбү Дауд, Тирмизи, Нәсаи әт-Таҗ том 1: 280

“Җомга хөтбәсенә соң килеп, кеше өстеннән атлап, аларга кыенлык тудыргучы кемсәләр, үзләренә җәһәннәмгә илткүче күпер салалар”[16].

“Хатыйб минбәргә чыккач кеше өстеннән атлап үзенә утырыр өчен урын эзләүчеләр, җәһәннәмдәге эче ярылып, бавырсаклары тышка атылган кемсә хәлендәдерләр”[17].

Минбәргә якын булу

Җомга хөтбәсе укынган вакытта имам һәм минбәргә якын булуның бөек бер әҗер булганлыгы турында сөекле пәйгамбәребез (сагв.) хәдис-и шәрифендә шулай дип хәбәр итә: **“Госел алып, мәчеткә килеп, имам якынында утырып, хөтбәне тавыш-тынсыз тыңлаучы кемсәнең, бу һәм үткән җомга арасында кылынган гөнаһлары өч каты белән гафу кылыныр”[18].**

Мисвак куллану

Фарыз һәм нәфилә намазлары алдыннан мисвак кулланып теш чистарту динебездә күркәм санаган эшләрдән. Кеше арасында, җәмагатьтә кылынган җомга намазында исә бу тагын да хуп күренә. Мисвак кулланып, теш чистарту турындагы хәдисләрендә пәйгамбәребез (сагв.) шулай дип әйтә:

---

[16] Тирмизи эт-Таҗ том 1: 289

[17] Әхмәд, Табәрани Тәҗрид тәрж. том 3: 68

[18]Муслим, Тирмизи эт-Таҗ том 1: 288

عن ابى هريرة رضى الله عنه قال: قال رسول الله (ص) فى جمعة من الجمع: معاشر المسلمين! ان هذا اليوم جعله الله لكم عيدا فاغتسلوا و عليكم بالسواك. رواه الطبرانى

“Мисвак белән теш чистартып кылынган намаз, бүтән намазлардан җитмеш тапкыр яхшырактыр”[19].

“Мисвак кулланып, тешләрегезне чистартыгыз, чөнки бу авызыгызның чиста булуына, Раббыгызның да разы булуына бер сәбәптер”[20].

“Әгәр дә мин өммәтемә мәшәкать тудырырга курыкмаса идем, мин аларга һәр намаз алдыннан тешләрен чистартырга әмер итәр идем”[21].

Хөтбәне тавыш-тынсыз тыңлау

Җомга хөтбәсе укынган вакытта тавыш-тынсыз калу - фарыз, сөйләшү исә – харам санала. Укынган хөтбәне хошуг эчендә тыңлау һәр мөселманның вазыфәсе. Моның турында хәдис-и шәрифләрдә шулай дип әйтелә:

“Җомга хөтбәсе укынган вакытта янындагыңа “сөйләшмә” – дип тә әйтсәң дә, гөнаһлы буш сүз сөйләгән булырсың”[23].

“Кем җомга хөтбәсе укынган вакытта “сөйләшмә” – дип кенә әйтсә дә, сүз сөйләгән булыр. Сүз сөйләү исә җомганың савабыннан мәһрүм итә”[24].

“Өч нәрсә бардыр ки, алардан сәламәт булган кешенең ике җомга арасындагы кылынган барлык гөнаһлары гафу кылыныр, болар: бүтәннәргә

---

[19] Әхмәд, Хәким Тәҗрид тәрҗ. том 3: 36
[20] Әхмәд Тәҗрид тәрҗ. том 3: 35
[21] Әхмәд Тәҗрид тәрҗ. том 3: 35
[23] Бухари, Муслим, Әбү Дауд, Тирмизи, Нәсаи әт-Таҗ том 1: 288
[24] Әхмәд Тәҗрид тәрҗ. том 3: 101

кыенчылык китерү, сүз сөйләү һәм сүз сөйләүчегә “сөләшмә” – дип әйтү”[25].

Догалар кабул булу сәгатенә ирешү

Җомга көне эчендә бөтен догалар кабул булган бер сәгать бардыр ки, бу сәгатькә догалар кабул булу сәгате дип әйтелә. Бу сәгатьнең җомга көненең кайсы сәгатендә булганлыгы турында төрле фикерләр бар. Боларның иң ышанычлысы, имамның минбәргә чыгып, җомга намазын кылдырып бетергәнчегә хәтлек булган вакыт икәнлеген сөйләүче фикердер. Бу сәгатьтә чын күңелдән кылынган догаларның һичшиксез кабул булачаклары турында, кайбер хәдис-и шәрифләрдә шулай диелә:

عن ابى سعيد الخدرى و ابى هريرة رضى الله عنهما ان رسول الله(ص) قال: ان فى الجمعة الساعة لا يوافقها عبد مسلم يسأل الله عز و جل فيها الا اعطاه إياه و هى بعد العصر. رواه أحمد – وفى الرواية – **هى ما بين أن يجلس الامام الى ان تقضى الصلاة.** رواه مسلم

“Җомга көне эчендә андый бер сәгать бардыр ки, бу сәгатьтә намаз кылып, дога кылган һәрбер колның догалары Аллаһ тарафыннан һичшиксез кабул ителер”[26].

“Имамның минбәргә менеп, аның намаз кылдырып бетергәнчегә хәтлек вакыт – догаларның кабул булу сәгатедер”[27].

---

[25] Әхмәд Тәҗрид тәрҗ. том 3: 102
[26] Бухари, Муслим Рияд ас-Салихин тәрҗ. том 2: 444
[27] Муслим Рияд ас-Салихин тәрҗ. том 2: 445

Саләт вә сәләм китерү

Атнаның барлык көннәре арасында иң өстен булып саналгучы җомга көнендә Аллаһ рәсүленә (сагв.) күпләп саләт вә сәләм китерүнең фазыләте турында, сөекле пәйгабәребез (сагв.) нең шулай дип әйткәнлеге билгеле: **“Көннәрнең иң фазыләтлесе – җомга көнедер. Шуңа күрә бу көндә миңа күпләп саләт вә сәләм китерегез чөнки сезнең саләт вә сәләмнәрегез миңа ирешер”[28].**

“Җәннәттә миңа иң якын кеше, дөньяда миңа иң күп саләт вә сәләм китергәннәре булачактыр. Шуңа күрә кичләрнең һәм көннәрнең иң күркәмендә (җомга киче һәм көннендә) **миңа күпләп саләт вә сәләм китерегез”[29].**

Югарыда зикер кылынган хәдис-и шәрифләрдән аңлашылганча, җомга көннәрен рәсүлүллаһ (сагв.) кушканча каршылап, ул кушканча Аллаһ (сагв.) хозурында җомга хөтбәләрен тыңларга һәм намазларын кылу өчен килгән мөэминнәргә бөек әҗерләр бар. Иманның камиллеккә, рухның да җитлеккәнлеккә ирешүнең юлы – Аллаһ һәм Аның илчесе (сагв.) теләгәннәре кебек мөселман булуда.

Хатыйб диккәть итәргә тиешле хосуслар

Җомга намазыннан әввәл һәм бәйрәм намазларыннан соң минбәргә чыгып җәмагать алдында Аллаһка хәмд, рәсүлүллаһка (сагв.) саләт-ү вә сәләм китерәрәк, дини кагыйдәләргә мөнәсиб рәвештә ике бүлемлек әйтелгән сүзгә “хөтбә” исеме бирелер. Хөтбә укучы кемсәгә “хатыйб”

---

[28] Әбү Дауд Рияд ас-Салихин тәрж. том 2: 446

[29] Шәфигый, Бәйхаки әт-Таҗ том 1: 292

исеме бирелер. Хөтбә җомга намазының шартларыннан булып, зикер, гыйбәдәт һәм нәсихәтьтән гыйбарәт.

Пәйгамбәребез (сагв.) вакытыннан алып, безнең көнебезгә хәтле җомга намазы кылынган барлык урыннарда да хөтбә укылыр һәм бу кыяматкә кадәр дә шулай дәвам итәчәк. Бу сәбәптән, хөтбә, мөселманнарның дини һәм дөньяви тормышларына яктылык керткүче әһәмиятле бер вазыфә булып тора. Шуңа күрә хатыйбләр җилкәсенә бөек бер җаваплылык йөкләнә. Ислам китергән җәмгыять төзелеше планын кешеләргә таныту белән вазыфәләндерелгән хатыйб, тема сайлаеш һәм тәкъдим ителешендә булсын мы, яки үз яшәешендә булсын, бик игътибарлы булырга тиеш. Чөнки хатыйблык матур сөйли белү генә түгел, сөйләгәннәрне гамәлгә ошыра белү дә.

Аллаһ биргән Ислами тормыш рәвешен кешеләргә танытып җиткерү белән вазыфәләндерелгән хатыйбларның бу вазыфәләре шуның хәтле шәрәфле һәм җаваплыдыр ки, бу вазыфәләрен уңышлы башкара белүләре өчен, аларга кайбер хосусларга игътибар итәргә тиеш. Без бу хосусларны аста кыскача санап чыгарга уйладык:

1-Хатыйб камил бер иман кешесе булырга тиеш.

Кальб һәм вожданнарга иман урнаштыру белән вазыфәләндерелгән хатыйб, иң әввәл, үзе җитлеккән, тирән, җанлы һәм тере бер иманга сахыйб булырга тиеш. Сөйләнгән сүзләрнең җәмагатьтә тәэсир калдыра белүләре өчен, хатыйбта мондый чиста бер иманның булуы иң беренче бер шарт.

2-**Хатыйб ныклы гыйлем кешесе булырга тиеш.**

Гыйльми көче булмаган бер хатыйбның уңышлы булуы мөмкин түгел. Сөйләгәннәренең мәгънәсен үзе белмәгән кемсә башкаларга ни нәрсә бирә ала? Шуңа күрә хатыйб Ислами гыйлем һәм хитабәт ысулларын белү белән берлектә, югары культура кешесе дә булырга тиеш.

3-**Хатыйб чиста күңелле һәм чамалы кеше булырга тиеш.**

Чиста күңеллелек, әйтелгән һәр сүз белән Аллаһ ризасын эзләү димәктер. Моны йөрәге белән сизеп, аңлаучы хатыйб, рәнҗетүче һәм ерагайтучы сүз һәм хәрәкәтләрдән ерак торып, фетнә һәм фәсәд уятмыйча, Аллаһ динен сөйдерә һәм уйландыра торган бер рәвештә аңлатырга тырышачак.

4-Хатыйб сөйләгәннәре белән гамәл итәчәк.

Сөйләгәннәре белән тормышында гамәл итмәгән, яшәеше сөйләгәннәрен ялганнаган бер хатыйбны, җәмагатьнең җитдигә алуы мөмкин түгел. Мондый имам бөек бер бәла эчендә булып, сөйләгәннәре дә буш бер сүздер.

5-**Хатыйб вазыфәсен яратырга, җәмагать алдына да сөенеп чыгарга тиеш.**

Эшен яратмаган, вазыфәсен дә бер йөк кебек ташыган бер хатыйбның җәмагатькә бирерлек нәрсәсе юк.

6-**Хатыйб чисталык һәм пөхтәлеккә диккать итәчәк.**

Хатыйбның сүзләре кебек үк, аның киеме һәм пөхтәлеге дә җәмагатьтә көчле тәэсир калдыра. Диелә белер ки, хатыйбның киеме һәм тышкы кыяфәте аның иң әввәл нәсихатедер. Шуңа күрә һөнәренең гыйззәт һәм шәрәфе турында уйлаган һәр хатыйб җәмагать алдына чиста һәм пөхтә кием киеп чыгачак. Тәрипсез яисә килешмәгән рәвештә җәмагать алдына чыгучы хатыйб, үзен баштан үк уңышсызлыкка дучар иткәнлеген аңларга тиеш.

7-**Хатыйб актуаль мәсьәләләр турында сөйләячәк.**

Чөнки актуаль мәсьәләләр, тыңлаучыларда көчлерәк тәэсир калдыра.

8-**Хатыйб хөтбәсен үзе әзерләргә тиеш.**

Хатыйб хөтбәсен башкаларның китапларыннан алган булса да, аны үз теле белән аңлатырга тырышырга тиеш.

Моны эшләгәндә, алдына чыгылачак җәмагатьнең аңлаеш һәм мәдәният дәрәҗәсен дә истә тотарга тиеш, чөнки боларны истә тотмыйча сөйләнелгән хөтбәләр, көтелгән нәтиҗәләргә китермәс.

9-Хатыйб сөйләгән хөтбәсен ныклы дәлилләр белән дәлилләячәк.

Моның өчен дә, хөтбә темасына кагылган аят-и кәримәләр һәм хәдис-и шәрифләрнең хөкемнәрен һәм мөҗтәһидләрнең фикерләрен яхшы беләчәк. Хөтбәсен тере тормыш мисаллары белән бизәп, артык хикәят сөйләүдән дә качыначак.

10-Хатыйб хөтбәсенә Исламга чит фикер кертмәячәк.

Сөйләгән һәр сүзе Ислам низамының җанлы, тере һәм коткаручы принципларын уртага салачак. Җомга көнендә Аллаһ хозурына җыелган мөэминнәргә Ислам китергән яшәү рәвешен аңлату белән йөкле булган бер хатыйб, буталчык фикерләр белән җәмагать каршысына чыга алмас һәм чыгарга тиеш тә түгел.

11-**Хатыйб хөтбәсен кыска һәм кызык тотарга тиеш.**

Моның турында хәдис-и шәрифтә шулай диелә:

“Кылган намазының озынлыгы һәм хөтбәсенең кыскалыгы кешенең аңлаешына күрсәтә. Шулай булгач намазларыгызны озынайтып, хөтбәләрегезне кыска тотыгыз”[30].

12-Хатыйб тавыш һәм сөйләвенә игътибарлы булырга тиеш.

Тавыш һәм сүзләрнең кеше миенә тәэсир итә белү көченә ия икәнлеген белеп торгучы хатыйб, колакларны кисүче югары тавыш һәм кискен авазлардан ерак булып, кирәкле

[30] Муслим, Әхмәд әт-Таҗ том 1: 282

урыннарда тавыш һәм сүзләрен татлы һәм тетрәндергеч итәчәк, ләкин артык хисләргә дә бирешмәячәк.

13-**Хатыйб хәрәкәт һәм мимикасына игътибар итәчәк.**

Хатыйбның хөтбә укыганда һич хәрәкәтсез калуы да дөрес түгел. Хатыйб кирәк урыннарда куллары белән дә хәрәкәт итеп, хөтбәгә җанлылык кертә белергә тиеш. Ләкин алай да, артык җитдиләнеп, мәчет тышындагыларга йодырык селкүдән качынырга тиеш. Шулай үк хатыйбның мимикасы да бик әһәмиятле, куркытып искәрткәндә чатылган кашлар яки сөенечле хәбәр турында сөйләгәндә көлемсәгән иреннәр, хатыйбның эчке хисләренә иң яхшы бер тәрҗеман.

Кыскача, мөэминнәрнең күңелләренә Ислам низамыннан өзекләр китерү белән вазыфәләндерелгән бер хатыйб, иманы, гыйлеме, гыйбәдәте, әхлакы, ихласлыгы, яшәеше, сөйләшүе, киенүе һәм һәр төр хәле белән мөкәммәл бер кеше булырга тиеш. Пәйгамбәрләр макамыннан мөэминнәргә хитаб итү шәрәфенә лаек булган бер хатыйб, бу шәрәфен сакларга тиеш. Хөтбәнең фарыз һәм сөннәтләренә игътибар итеп, Ислам әдәб һәм тәртибенчә, җитдият һәм чиста күңеллелек белән хөтбә укыган бер хатыйб, Аллаһ ризасын, нәбиләр нәбисенең (сагв.) ризасын һәм дә бөтен мөэминнәрнең мәһабәтен казана. Шуңа күрә уңышлы бер хатыйб була белү һәм җәмагатьтә уңай бер тәэсир калдыра белү өчен, югарыда санап киткән хосусларга игътибар итү тиешле.

Тырышлык һәм гайрәтләр бездән булса, ярдәм, һидаят һәм хөкем итү Аллаһка гына аит.

ادْعُ إِلِى سَبِيلِ رَبِّكَ بِالْحِكْمَةِ وَالْمَوْعِظَةِ الْحَسَنَةِ وَجَادِلْهُم بِالَّتِي هِيَ أَحْسَنُ إِنَّ رَبَّكَ هُوَ أَعْلَمُ بِمَن ضَلَّ عَن سَبِيلِهِ وَهُوَ أَعْلَمُ بِالْمُهْتَدِينَ

“Раббың юлына хикмәт һәм күркәм вагәз белән чакыр, алар белән күркәм бәхәс кенә тот. Шик юктыр ки, Раббың тугры юлдан тайпылганнарны белә, тугры юлдагыларны да Ул белгүче”[31].

يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا لِمَ تَقُولُونَ مَا لَا تَفْعَلُونَ

“Әй, иман иткүчеләр, нигә эшләмәгәннәрегез турында сүз йөртәсез!”[32].

فَبِمَا رَحْمَةٍ مِّنَ اللّهِ لِنتَ لَهُمْ وَلَوْ كُنتَ فَظًّا غَلِيظَ الْقَلْبِ لاَنفَضُّواْ مِنْ حَوْلِكَ

“Аллаһ рәхмәте беләндер ки, син аларга йомшак йөрәкле булдың. Югыйсә син каты бәгерле булса идең, алар, һичшиксез, күптән таралып киткән булырлар иде тирәңнән”[33].

Хәмд галәмнәрнең Раббысына – Аллаһка тиешле.

Хөтбәнең бүлемнәре һәм аның гарәпчә сөйләнгән өлешләре

Җомга намазының беренче дүрт рәкагать сөннәте кылынганнан соң, мөәззин “Әхзәб” сүрәсенең 56 атен укый башлый. Моның белән хатыйб урыныннан торып, минбәргә таба юнәлә. Минбәр алдында туктап, ул кулларын күтәрә һәм эченнән шушы доганы укый:

اَللَّهُمَّ يَا مُفْتِحَ الاَبْوَابِ اِفْتَحْ لَنَا خَيْرَ الْبَابِ ، اَللَّهْمَّ يَا مُحَوِّلَ الاَحْوَالِ حَوِّلْ حَالَنَا اِلَى اَحْسَنِ الْحَالِ ،

[31] Ән-Нәхл: 125
[32] Әс-Саф: 2
[33] Али Имран: 159

اَللّٰهُمَّ اغْفِرْ لَنَا وَارْحِمْنَا وَالْحِقْنَا بِالصَّالِحِينَ[34]

Бу доганы укыганнан соң, хатыйб минбәргә менә башлый һәм минбәрнең өченче басамагында туктап, эченнән шушы доганы укый:

رَبِّ اِشْرَحْلِي صَدْرِى وَيَسِّرْلِى اَمْرِى وَاحْلُلْ عُقْدَةً مِنْ لِسَانِى يَفْقَهُوا قَوْلِى ، رَبِّ قَدْ اَتَيْتَنِى مِنَ الْمُلْكِ وَ عَلَّمْتَنِى مِنْ تَأْوِلِ الاَحَادِثِ ، اَللّٰهُمَّ صَلِّ وَسَلِّمْ عَلَى عَبْدِكَ وَرَسُولِكَ مُحَمَّدٍ وَعَلَى اَلِهِ وَصَحْبِهِ اَجْمَعْينَ.

Хатыйб хөтбә укыначак җиденче басамакка җиткәч, эченнән шушы доганы укый:

اَللّٰهُمَّ هَذَا الْمَكَان لَيْسَ بِمَكَانِى وَهَذَا الشَّأْن لَيْسَ بِشَأْنِى اَللّٰهُمَّ يَسِّرْلِى اَمْرِى وَاَصْلِحْ لِى دِينِى اَللّٰهُمَّ اَغْفِرْلِى خَطِيئَتِى وَجَهْلِى وَاِسْرَافِى فِي اَمْرِى اَللّٰهُمَّ تَقَبَّلْ دُعَائِى بِحُرْمَةِ سَيِّدِنَا سَيِّدِ الْمُرْسَلِين وَالْحَمْدُ لِلّٰهِ رَبِّ الْعَالَمِينَ.

Хатыйб бу доганы укыганнан соң, җәмагатькә йөзе белән борылып утыра да, икенче (мәчәт) азанын тыңлый башлый. Аннары аякка баса да, мәчеттәгеләргә ишетерлек итеп беренче хөтбәнең гарәпчә өлешен укый башлый:

اَلْحَمْدُ لِلّٰهِ اِنَّ الْحَمْدُ لِلّٰهِ نَحْمَدُهُ نَسْتَعِينُهُ وَنَسْتَغْفِرُهُ وَنَعُوذُ بِاللّٰهِ مِنْ شُرُورِ اَنْفُسِنَا وَمِنْ سَيِّئَاتِ اَعْمَالِنَا ، مَنْ يَهْدِهِ اللّٰهُ فَلاَ مُضِلَّ لَهُ وَمَنْ يُضْلِلْ فَلاَ هَادِىَ لَهُ ، نَشْهَدُ اَنْ لاَ اِلَهَ اِلاَّ اللّٰهُ وَحْدَهُ لاَ شَرِيكَ لَهُ لَهُ الْمُلْكُ وَلَهُ الْحَمْدُ وَهُوَ عَلَى كُلِّ شَيْءٍ قَدِير ، وَنَشْهَدُ اَنَّ سَيِّدِنَا مُحَمَّدًا عَبْدُهُ وَحَبِيبُهُ وَرَسُولُهُ اَكْرَمَ رَسُولِ

[34] Минбәргә чыкканда һәм ике хөтбә арасында утырганда укынган аерым бер дога булмаганга күрә, хатыйбүзе теләгән доганы укый.

وَخَيْرَ بَشِيرٍ وَ نَذِيرٍ ، اَللّٰهُمَّ صَلِّ وَسَلِّمْ وَبَارِك عَلَى سَيِّدِنَا مُحَمَّدٍ وَعَلَى اَلِهِ وَصَحْبِهِ اَجْمَعْينَ. اَمَّا بَعْدُ : اِنَّ اَصْدَقَ الْحَدِيثِ كِتَابَ اللهِ، وَاَحْسَنَ الْهَدْيِ هَدْىُ مُحَمَّدٍ ، وَشَرَّ الاُمُورِ مُحْدَثَتُهَا ، وَكُلُّ مُحْدَثَةٍ بِدْعَة ، وَكُلُّ بِدْعَةٍ ضَلاَلَةٌ ، وَكُلُّ ضَلاَلَةٍ فِى النَّارِ. اِتَّقُوا اللهَ يَا عِبَادَ اللهِ اُصِيكُمْ بِتَقْوَى اللهِ وَطَاعَتِهِ ، اِنَّ اللهَ مَعَ الَّذِينَ اِتَّقَوْا وَالَّذِينَ هُمْ مُحْسِنُونَ. قَالَ اللهُ تَعَالَى فِى كِتَابِهِ الْكَرِيم ، اَعُوذُ بِاللهِ مِنَ الشَّيْطَانِ الرَّجِيم – بِسْمِ اللهِ الرَّحْمَنِ الرَّحِيمِ...

Хатыйб беренче хөтбәнең бу гарәпчә өлешен укыганнан соң, укыначак хөтбәнең аят һәм хәдисләрен укып китә. Артыннан да үз телендә хөтбәсен укыр. Иң соңында да шушы сүзләрне әйтә:

اَلاَ اِنَّ اَحْسَنَ الْكَلاَمِ وَاَبْلَغَ الْنِظَامِ كَلاَمَ اللهِ الْمَلِكِ الْعَزِيزِ الْعَلاَّمِ كَمَا قَالَ تَبَارَكَ وَتَعَالَى فِى اَلْكَلاَمِ ، وَاِذَا قُرِاَ الْقُرْاَن فَاسْتَمِعُوا لَهُ وَاَنْصِتُوا لَعَلَّكُمْ تُرْحَمُون . اَعُوذُ بِاللهِ مِنَ الشَّيْطَانِ الرَّجِيم – بِسْمِ اللهِ الرَّحْمَنِ الرَّحِيمِ.

Моннан соң хатыйб һәр хөтбәнең ахырында укынган аят-и кәримәне укый да, эченнән шушы доганы әйтә:

بَارَكَ اللهُ لَنَا وَلَكُمْ وَلِسَائِرِ الْمُؤْمِنِينَ وَالْمُؤْمِنَاتِ وَالْمُسْلِمِينَ وَالْمُسْلِمَاتِ اَلاَحْيَاءِ مِنْهُمْ وَالاَمْوَاتِ بِفَضْلِهِ وَرَحْمَتِهِ اِنَّهُ قَرِيب مُجِيبُ الدَّعَوَاتِ.

Бу доганы укыганнан соң, хатыйб аякка баса да, мәчеттәгеләргә ишетерлек итеп шушы сүзләре белән икенче хөтбәсен башлый:

اَلْحَمْدُ لِلَّهِ حَمْدَا الْكَامِلِينَ وَالصَّلاَةُ وَالسَّلاَمُ عَلَى رَسُولِنَا مُحَمَّدٍ وَعَلَى اَلِهِ وَاصْحَبِهِ اَجْمَعِينَ ، تَعْظِيمًا لِنَبِيِّهِ وَتَكْرِيمًا لِفَخَامَةِ

شَانِ شَرَفِ صَفِيِّهِ فَقَالَ عَزَّ وَجَلَّ مِنْ قَائِلٍ مُخْبِرًا وَاَمِرًا ،اِنَّ اللّٰهُ وَمَلَئِكَتَهُ يُصَلُّونَ عَلَى النَّبِىِّ يَااَيُّهَا الَّذِينَ اٰمَنُوا صَلُّوا عَلَيْهِ وَسَلِّمُوا تَسْلِيمًا ، اَللّٰهُمَّ صَلِّ وَسَلِّمْ عَلَى سَيِّدِنَا مُحَمَّدٍ وَعَلَى اٰلِهِ وَصَحْبِهِ اَجْمَعِينَ كَمَا صَلَّيْتَ ...الخ. اَللّٰهُمَّ بَارِك عَلَى سَيِّدِنَا مُحَمَّدٍ وَعَلَى اٰلِهِ وَصَحْبِهِ اَجْمَعِينَ كَمَا بَارَكْتَ... الخ.

Моннан соң хатыйб кулларын күтәреп, бераз түбәнерәк тавыш белән шушы доганы укый:

اَللّٰهُمَّ وَارْضِ عَنْ الاَرْبَعَةِ الْخُلَفَاءِ سَيِّدِنَا اَبِى بَكْرٍ وَعُمَرَ وَعُثْمَان وَعَلِى ذَوِى الصِّدْقِ وَالْوَفَاءِ وَبَقِيَّةِ الْعَشَرَةِ الْمُبَشَّرَةِ وَاٰلِ بَيْتِ الْمُصْطَفَى وَعَنِ الاَنْصَارِ وَالْمُهَاجِرِينَ وَالتَّابِعِينَ اِلَى يَوْمِ الْجَزَاءِ ، اَللّٰهُمَّ اِغْفِرْ لِلْمُؤْمِنِينَ وَالْمُؤْمِنَاتِ وَالْمُسْلِمِينَ وَالْمُسْلِمَاتِ اَلاَحْيَاءِ مِنْهُمْ وَالاَمْوَاتِ ،اَللّٰهُمَّ رَبَّنَا اٰتِنَا فِى الدُّنْيَا حَسَنَةً وَفِى الاٰخِرَةِ حَسَنَةً وَقِنَا عَذَابَ النَّارِ بِرَحْمَتِكَ يَا اَرْحَمَ الرَّاحِمِينَ وَسَلاَمٌ عَلَى الْمُرْسَلِينَ وَالْحَمْدُ لِلّٰهِ رَبِّ الْعَالَمِينَ.

Моннан соң хатыйб, эченнән “әгүзе-бисмилла” әйтеп, мәчеттәгеләргә ишетерлек итеп шушы аят-и кәримәне укый да, минбәрдән инеп, җомга намазын кылдыра:[35]

اِنَّ اللّٰهَ يَاْمُرُ بِالْعَدْلِ وَالاِحْسَانِ وَاِيتَاءِ ذِى الْقُرْبَى وَيَنْهَى عَنِ الْفَحْشَاءِ وَالْمُنْكَرِ وَالْبَغْىِ يَعِظُكُمْ لَعَلَّكُمْ تَذَكَّرُونَ.[36]

---

[35] Бәйрәм хөтбәләрендә бу аят урынына Исра сүрәсенең соңгы аят-и кәримәсе укыла.

[36] Ән-Нәхл: 90